ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 152 от « 18 » 07 2024 г.

Мамадыш муниципаль районы башлыгының 2014 елның 31 декабрендәге 108 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы һәм Мамадыш муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затларының халыктан кергән мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (2020 елның 13 февралендәге 012 номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 27 ноябрендәге 355-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 9 декабрьдәге 2023 елның 9 декабрендәге124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Мамадыш муниципаль районы башлыгының 2014 елның 31 декабрендәге 108 номерлы карары (2020 елның 13 февралендәге 012 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы һәм Мамадыш муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затларының халыктан кергән мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

000169

1.1. 1 бүлекнең 1.2 пунктының 2 һәм 3 абзацында «электрон почта адресы» сүзләреннән соң «яисә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланганда шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификаторын) » сүзләрен өстәргә;

1.2. 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 2.17 пункт өстәргә:

«2.17. Россия Федерациясенең миграция өлкәсендәге законнарын бозу очраклары турындагы мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып биш көн эчендә эчке эшләр өлкәсендәге башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органына һәм (Башлыгы) Татарстан Республикасы Рәисенә мөрәҗәгать җибәргән гражданның мөрәҗәгатен җибәрү турында хәбәр итүе белән җибәрелә.».

1.3. 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 4.12 пункт өстәргә:

«4.12. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм мондый балаларны озата баручы затлар ия. Әгәр чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына бер үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү шәхси кабул итүгә килү тәртибендә башкарыла.»;

1.4. пункт 4.8. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар булганнар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүче вәкилләре;

3) I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) кабул итүгә 3 яшькә кадәрге балалар белән килгән гражданнар.

Әгәр беренче чираттагы шәхси кабул итү хокукына бер үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү шәхси кабул итүгә килү тәртибендә башкарыла.»;

1.5. 4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Шәхси кабул итү вакытында 4.8 пунктының 1-4 пунктчаларында һәм 4.12 пунктында күрсәтелгән гражданнар чираттан тыш яки беренче чираттагы шәхси кабул итүгә хокукларын раслаучы документ күрсәтәләр.»;

1.6. 4.11 пунктны үз көчен югалтты дип танырга;

1.7. 5.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең торышы (гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау) муниципаль район башлыгының еллык хисабында чагыла һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырыла. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү турындагы статистик мәгълүматлар, шулай ук гражданнарның бердәм кабул итү көнен үткәрү турындагы мәгълүматлар Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә елына ике тапкыр, кушымта формалары буенча яртыеллыкның соңгы аеннан соң килә торган айның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла (кушымталар N 3, 4).»;

1.8. Тәртипнең 3 кушымтасындагы «Мамадыш муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында статистик мәгълүматлар» Мамадыш муниципаль районы башлыгы һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта);

1.9. карарга кушымта формасы буенча гражданнарны кабул итүнең бердәм көнен үткәрү турында мәгълүматны 4 нче кушымта итеп өстәргә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары　　　　　　　　　　　　　　　Р.Р. Сәмигуллин

**Мамадыш муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында статистик мәгълүматлар**

| Район һәм шәһәрләр исеме | Барлыгы мөрәҗәгатьләр килде (язма һәм телдән*** мөрәҗәгать) | | Электрон мөрәҗәгатьләр килде (Интернет кабул итү, электрон почта)**** | | Кире элемтә аша (Платформа обратной связи)***** | | Вшул исәптән җитәкчелеккә җиткерелде****** | | контрольгә алынды | | Уңай хәл ителде | | Урынга чыгып тикшерелде | | шәхси кабл итүдә кабул ителгән гражданнар | | шул исәптән җитәкчеләр****** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 20__ ел | 20__ел | 20__ ел | 20__ ел | 20__ел | 20__ел | 20__ел | 20__ ел | 20__ ел | 20__ ел | 20__ел | 20__ ел | 20__ел | 20__ ел | 20__ел | 20__ел | 20__ ел | 20__ел |
| Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Искәрмә:

Мәгълүматлар «______»___________20___ елдан «____»________20__ елга кадәр

. ** Муниципаль район, шәһәр округы органнары муниципаль берәмлек Советы һәм башкарма комитеты.

*** Телдән мөрәҗәгать итү: шәхси кабул итү һәм телефон шалтырату

**** Электрон мөрәҗәгатьләр язма мөрәҗәгатьләр санына керә.

***** ПОС аша килгән мөрәҗәгатьләр язма мөрәҗәгатьләр санына керә

****** Җитәкчелек муниципаль берәмлек башлыгы һәм муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе.

*2 нче кушымта*

**Мамадыш муниципаль районы Советында гражданнарны кабул итүнең бердәм көнен үткәрү турында мәгълүмат**
**«_____» _______20___ алып «____»________20__ елга кадәр**

| № | Район исеме | Кабул итү саны | Шул исәптән җитәкче белән | | Кабул ителгән гражданнар саны | Шул исәптән җитәкчелек тарафынннан | | Урынга чыгып кбул итү саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Башлык | РИК | | Глава | РИК | |
| | Мамадыш муниципаль районы | | | | | | | |